КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 август

г.Казань

№ 612

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км– 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII1 бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 декабрь, 2668-б номерлы, 2023 ел, 8 декабрь, 2800-б номерлы боерыклары, 2022 елның 11 гыйнварындагы КС-17/98 номерлы концессион килешү нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Автострада» акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасының Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) - Баулы (М-5)». 3 нче этап - 89+641 км - 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск - Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Карамыш авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, гражданин Г.Г.Гомәров (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган, 120 000 кв.метр мәйданлы, 16:41:030304:107 кадастр номерлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлегеннән барлыкка килгән 3 246 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Кушымтада күрсәтелгән, җир кишәрлегендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районындагы Карамыш авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Автострада» акционерлык җәмгыятенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлегенең хокук иясе тарафыннан кул куелган килешү законнарда билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. «Автострада» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 3 нче этап – 89+641 км – 145+143 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын урнаштыру карала торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2022 ел, 25 ноябрь, 1262 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә 16:41:030304:107 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләү күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 1 август, 612 нче
карарына кушымта

Җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|
| 16:41:030304:107 | 16:41:000000:1622 | «Акъяр - Чирмешән - Шонталы» - Карамыш  - Яшәүче» автомобиль юлы |
| | 16:00:000000:68645 | «Студено-Ключевская» котельныена илтүдән алып «Грядинская», «Архангельская» котельныйларына кадәр, Татарстан Республикасы» |
| | 16:00:000000:68646 | «Архангельская» котельныена кадәр техник суны җиткерү |
| | 16:00:000000:68750 | «Көньяк Екатериновка югары үзле нефть ятмасының Көньяк Екатериновка күтәрелеген төзекләндерү» |
| | 16:00:000000:68781 | «Көньяк Екатериновка» котельные» |

_________________________________